ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТЕЛӘКӘЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423749, Иске Теләкәй авылы,
Үзәк ур.,87 нче йорт.
Тел. 3-44-59

СОВЕТ ТЛЯКЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423749, село Старое Тлякеево,
ул. Центральная, дом 87.
Тел. 3-44-59

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«08» ноябрь 2024 ел** **№ 20**

**«Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 марты 4 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә рәисләренең, рәис урынбасарларының, контроль-хисап органнары аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 26 сентябрендәге 829 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.04.2018 № 281, 14.06.2018 № 481, 17.10.2018 № 940, 29.12.2018 № 1320, 17.11.2021 № 1087, 13.12.2021 № 1222, 17.09.2022 № 1015, 30.04.2024 № 290, 24.06.2024 № 451 карарлары, кертелгән үзгәрешләр белән), Актаныш муниципаль районының Теләкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Теләкәй авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районының Теләкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2023 елның 27 март 4 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «13323» саннарын «13990» саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән карарга 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Теләкәй авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Х.Н.Гатауллин**

Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге Советы карарына 27.03.2023 ел, № 4
3 нче кушымта (Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге Советы 25.06.2024 №11 карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлек башлыкларының, депутатларының, авыл җирлекләрендә даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре**

| Вазыйфа атамасы | Айлык акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) | | |
|---|---|---|---|
| | авыл җирлекләрендә | | |
| | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 22 810 | 10 991 | 19 173 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 16 995 | 15 085 | 13 991 |
| Депутат | 13 990 | 13 990 | 13 990 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 13 990 | 13 990 | 13 990 |